Ландыш Заһретдинова

# «ФАТИРНИК» ФОРМАТЫНДА БИКАФЕСТ




«Сәләт» җитәкчеләре, активистлары тарафыннан ел дәвамында иң шәп проектлар, гаҗәеп масштаблы форумнар, зур-зур фестивальләр, мавыктыргыч кичәләр, үзенчәлекле дебатлар, кызыклы очрашулар, уникаль дәресләр, ягъни заманча чаралар үткәрелеп килә. Шундый шәп чараларның берсе – Рөстәм Бикмуллин исемендәге фестиваль. Иҗат куәсе булган сәләтле яшьләр һәм балалар аны һәр елны түземсезлек белән көтеп ала һәм Бикафест дип атый. Әлеге фестиваль хакында Бикафестның башкарма директоры Руфат Кыямов белән сөйләштек.

**Руфат, Бикафестның беренче адымнары ничек ясалган?**

Әлеге фестиваль катнашучыларны палатка, гитара, учак янына уналты ел элек үк җыя иде. Баштарак бу чара шәһәрдән читтә бик кечкенә форматта үткәрелгән. Монда сәләтле балалар, талантлы студентлар катнашкан. Уеннар, конкурслар учак янында җырлашулар, гитарада уйнаулар белән үрелеп барган. Хәзер исә әлеге фестиваль ярымпрофессионаллар катнаша торган зур бәйге, массакүләм чарага әйләнде. Катнашучылар – концертларда, олы сәхнәләрдә чыгыш ясау тәҗрибәсе булган кешеләр. Соңгы өч ел дәвамында фестиваль КФУның Татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар институты бинасында уздырылып килде. Быел форматны тулысынча үзгәрттек, «фатирник» рәвешендә эшләдек. Җылы, рухи гаилә атмосферасы тудырырга булдык. Гала-концертны «Сәләт» Йортында уздырдык. Матур сәхнә ясадык, бөтен залны бизәдек. Артистлар чыгышларының сыйфаты, үзара көндәшлек һәм иңиңә булырга омтылыш сакланды.

**Ни өчен фестиваль Рөстәм Бикмуллин исемен йөртә?**

1994-1995 елларда бер төркем активистлар «Сәләт»не оештыра. Рөстәм Бикмуллин «Сәләт»кә зур өлеш керткән шундый шәхесләрнең берсе. «Сәләт»не үстерү, таныту өчен зур тырышлык куйган. Гитара, учак, палатка аның тормышының аерылгысыз өлешен алып торган. Ул гитарада уйнап җырлар иҗат иткән, шигырьләр сөйләгән. Аны белгән кешеләр, ул гитарада уйнап бард җырлаганда йөрәк табан астына китә иде, дип әйтә. Менә шуңа күрә фестиваль аның исеме белән йөртелә.

**Иҗади конкурслар бик күп. Бикафест ни белән аерыла, үзенчәлеге нидә?**

Фестиваль поэзия һәм вокал, музыка юнәлешендә эзләнә. Ни белән аерыла? Атмосфера белән! Монда беренче урында гаилә атмосферасын тудыру тора. Көндәшлек, беренче булырга омтылыш ничектер күләгәдә кала. Нәкъ менә иҗат итәргә теләк, иҗат җимешләреңне күрсәтергә омтылу һәм шул ук вакытта зур гаилә атмосферасында булу – фестивальнең төп үзенчәлеге. Башка конкурсларда, ата-аналар килеп, нишләп минем кызым беренче түгел, икенче генә, дип йөрергә мөмкин. Ә монда унынчы, унберенче бул, иң мөһиме – син чарага үз өлешеңне керттең һәм шунлыктан горурлык хисләре кичерәсең.

**Быелгы конкурс турында сөйләгез әле. Кемнәр катнашты, алар кайдан?**

Катнашучылар алты номинациядә көч сынашты. Поэзиядә: «Башка автор әсәрен яттан укучы», «Үз әсәрен иң оста яттан укучы» билгеләнде. Соңгысына аеруча зур игътибар бирелде, чөнки һәр кеше дә әсәр иҗат итми һәм үзе иҗат иткәнне сәнгатьле

Фото Руфат Кыямовның шәхси архивыннан алынды

итеп сөйли алмый. Вокал буенча дүрт номинациядә көч сынаштылар: «Иң оста автор башкаручы», «Иң оста коллектив башкаручы», «Татар халык җырын иң оста башкаручы», «Татар композиторларының академик әсәрен иң оста башкаручы».

Фестивальдә уникедән алып утыз яшькәчә кешеләр катнашты. Күбесе Казаннан иде. Татарстан районнары һәм шәһәрләреннән, Башкортстаннан да килделәр. Мәктәп укучылары, көллият, техникум, университет, консерватория студентлары катнашты.

Татар эстрадасы җырларын башкару номинациясендә катнашучылар күбрәк иде. Шигърияттә башка авторның шигырен укучылар байтак булды.

**Катнашучыларны ничек сайлап алдыгыз?**

Башта гариза бирү кампаниясен игълан иттек. Йөз сиксән заявка килде. Һәрберсенә шылтыратып чакырдык. Йөз егермеләп катнашучы сайлап алу этабын үтте. Мастер-класслар оештырылды. Театрга багышланганын Лилия Әхмәтҗанова алып барды. Видео-блогингны «Шикәрные» төркеме егетләре – Туран һәм Ислам оештырды.

Сайлап алу этабы бер көндә, иртәдән кичкә кадәр дәвам итте. Жюри әгъзалары арасында Рәмис Аймәт, Йолдыз Миңнуллина, Ләйсән Арсентьева, Илназ Сафиуллин һ.б. бар иде. Җиңүчеләрне сайлаганда каты дискуссия, диалоглар, батталийлар барды, бик кызыклы булды. Йомшак чыгышлар юк иде.

**Җиңүчеләр кемнәр?**

Сайлап алу этабында ничек чыгыш ясасам да ярый, дип әйтүчеләр үтә алмас иде. Шуңа күрә катнашучыларга: башта ук үзегезне тулысынча күрсәтергә тырышыгыз, дидек.

Үз җыры белән чыгыш ясаган Илдар Насыйров исемле егет икенче урын алды. Шулкадәр эмоциональ, бөтен күңелен биреп, ышанып җырлады – бик шәп иде. Концертта чәчәк кебек тулысынча ачылды: матурлыгын тамашачы да күрде.

Консерватория студенты Айназ Ахунов үзенең баянчысы белән чыгыш ясады – атмосфера егылып китәрлек шәп булды. Сәхнәгә чыгучыларның бусы – җиңүче, бусы – юк, дип әйтә алмыйм. Беренчеләр көчле дә, икенче-өченче урын алучылар йомшаграк дип әйтмәс идем, һәркайсы югары дәрәҗәдә. Бары тик кемгәдер күбрәк, кемгәдер азрак уңыш елмайды.

**Гала-концертка чыгыш ясарга җиңүчеләрне генә чакырдыгызмы?**

Жюри, концертка «фатирник» форматына туры килә торган номерларны сайлап алды. Җиңүчеләр – утыз кеше, концертка унөч номер гына керде. Матур, төзек, кызыклы килеп чыкты. Концертта чыгыш ясау – шулай ук җиңү. Әйтергә теләгәнеңне тамашачыга җиткерү – зур нәрсә.

Концерт бик югары дәрәҗәдә үтте. Катнашучылар профессионаллар булмаса да, үзләрен һөнәрләренең иң шәп осталары кебек тоттылар, чыгыш ясадылар.

**Туй үпкәсез булмый, диләр, Эх, менә шул урынын эшләп бетерәсе булган дигән әйбер калдымы?**

Бәлки бард җырларын башкаручыларны чакырырга кирәк булгандыр. Бауман урамында гитарада, виолончельдә классик музыка уйнаучылар турында әйтүем. Алар да артистлар бит, үзләрен урамда күрсәтәләр. Бәлки аларга да менә шундый фестиваль үтүен әйтергә кирәк булгандыр. Ә болай алга куйган максатларга тулысынча ирештек.

**Шушы концертны оештыруда Сезнең тарафтан нинди эшләр башкарылды?**

Аһ, бик күп! Бикафестны үткәрү өчен иң беренче эш итеп Игорь абый Смирнов белән бергә команда тупладык. Гариза бирү кампаниясеннән алып, концертны тәмамлагандагы соңгы сүзләргә кадәр – командабыз тырышлыгы. Сайлап алу турын ничек ясау; жюриларны чакыру, аларның кайда утыруы; модератор, алып баручы нәрсә әйтә; концерт, ачылыш ничек була; сценарий язу; анда фотоны җибәрергә, монда видео ясарга; микрофон куярга, номер кая китә; бүләкләүгә ничек чыгарга; паузаны кайда һәм ничек ясарга; кеше кая утыра: пуфиклар, урындыклар бармы; шарлар урынындамы, гирлянда янамы, чәчкәләр алынганмы, ашарга пешерелгәнме... – миллион мәсьәлә. Командадагы утызлап кеше һәрберсе үз бурычын үтәде. Команда шәп иде, гармониядә эшләдек.

**Бикмуллин фестивале киләсе елларда дәвам итәчәкме? Шәхсән Сез әлеге конкурсның киләчәген ничек күзаллыйсыз?**

Икенче елга бу фестиваль һәм сыйфат, һәм катнашучылар, һәм география ягыннан үсәчәк дип уйлыйм. Күпкә масштаблырак булачак. Фестивальне җәй көне зурлап үткәрсәк, бик шәп булыр иде, минемчә. Биш йөзләп кеше катнашырлык шартлар тудырсак... Бикафест кебек фестивальләрдән чыккан татар төркемнәре бар. Шуларның барысын да җыярга һәм күрсәтергә иде. Үзенчәлекле, креатив, бүтән төбәкләргә дә үрнәк булырлык зур фестивальгә әверелдерәсе иде. Артист үзе яңалык уйлап табып, шуны үзе күрсәтсә – бик шәп, дип уйлыйм.